Республика Татарстан
**ГЛАВА**
Пестречинского
муниципального района –
председатель Совета
Пестречинского
муниципального района
422770, с.Пестрецы, ул. Советская, 18

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы

**БАШЛЫГЫ –**

Питрәч муниципаль район
Советы рәисе
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» август, 2021 ел № 117-п

Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге адресы буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы дәүләт милкендәге җирләр (бүленмәгән) кадастр номеры 16:33:080702:496 белән булган җир кишәрлеген яңадан бүлү максатында территорияне ызанлау проектын раслау мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында гавами тыңлауларны, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 30 гыйнварындагы 3/224 номерлы карары (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2017 елның 07 декабрендәге 120 номерлы, 2019 елның 25 июлендәге 211 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән), гр. Газизова Эльвира Рифкатовнаның мөрәҗәгатен исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге адресы буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы дәүләт милкендәге җирләр (бүленмәгән) кадастр номеры 16:33:080702:496 белән булган җир кишәрлеген яңадан бүлү максатында территорияне ызанлау проектын раслау мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- иҗтимагый фикер алышуларын үткәрү урыны - Питрәч районы, Питрәч ав., Совет ур., 34 йорт (2 кат, 1 каб.);

- иҗтимагый фикер алышуларын уздыру вакыты - 13.00 сәгать.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасын – иҗтимагый фикер алышуларны әзерләү һәм үткәрү өчен җаваплы итеп билгеләргә.

4. Иҗтимагый фикер алышуларда катнашу өчен гаризалар, иҗтимагый фикер алышулар сораулары буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Питрәч районы, Питрәч авылы, Совет урамы, 34 йорт, 2 кат,каб. №1).

Гаризалар, гражданнар өчен мәҗбүри күрсәтеп, 2021 елның 16 августыннан 16 сентябренә кадәр, эш көннәрендә 09.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, 14.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, теркәлү (яшәү урыны), эшләү урыны һәм биләгән вазыйфалар, контакт телефоннары; гражданнар төркеме өчен - фамилияләр, исемнәр, аталарының исемнәре, нинди дә булса иҗтимагый оешмаларга яисә берләшмәләргә (булган очракта), теркәү адреслары (яшәү урыны), контакт телефоннары, юридик затлар өчен оешмалар бланкында, җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелә.

5. Питрәч муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына, 2021 елның 16 августына кадәр Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы сайтында (http://www.pestreci.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге адресы буенча Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы дәүләт милкендәге җирләр (бүленмәгән) кадастр номеры 16:33:080702:496 белән булган җир кишәрлеген яңадан бүлү максатында территорияне ызанлау проектын раслау мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында карар проектын урнаштырырга.

4. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы сайтында (http://www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы башлыгы СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА И.М. Кашапов